РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА КУЛЬБАЕВО-МАРАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Колбай-Мораса ав.

КАРАР

«30» октябрь 2020 ел

№ 3

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегенең Колбай-Мораса авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мараса авылы, Ленин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мараса авылы Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат районы Колбай-Мораса авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ленин һәм Елга арьягы урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2020 елның 12 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мараса авылы, Ленин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мараса авылы Мәдәният йорты бинасында Колбай-Мараса авылында Мәктәп һәм Яшеллек урамнарында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2020 елның 13 нче ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мараса авылы, Ленин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мараса авылы Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылының Пионер һәм Тукай урамнарында яшәүчеләр өчен гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2020 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Колбай-Мараса авылы, Ленин урамы, 30 нчы йорт адресы буенча урнашкан Колбай-Мараса авылы Мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы, Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылының Яр буе урамы, Мичурин, Бакча урамнарында яшәүчеләр өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен бүләргә.

6. Колбай-Мораса авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыруны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Колбай-Мораса авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса Колбай-Мораса авыл җирлеге торак пункты чикләрендә юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

- Колбай-Мораса авылында су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;

- Колбай-Мораса авылында янгын сүндерү гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru., Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Насыйбуллин